Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Кодаш авыл җирлегенең Иске Кызылъяр торак пунктында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 елның16 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирлеүзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидар әтурында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлегенең Иске Кызылъяр авылында гражданнар җыены **карар бирде**:

1. Кодаш авыл җирлеге Иске Кызылъяр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 2020 елда 500 сум күләмендә үзарасалым акчасын кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

-Иске Кызылъяр авылының Гобәйди урамына вак таш җәю.

-Иске Кызылъяр авылына су башнясына насос алу.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Кодаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру,http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы Ф.М. ШАКИРОВ

Совет Кудашевского сельского поселения
Кодаш авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002501
АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ